## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

## ОЛЫ МИШӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ
## КАРАР

унбишенче утырыш өченче чакырылыш

« 16 » декабрь 2016 ел № 47 Олы Мишә ав.

Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге Советының «Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм территорияләр объектларына якындагы территорияләрне билгеләү турында» 2013 елның 29 июлендәге 92 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында» 1995 елның 22 декабрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 27 декабрендәге 1425 номерлы «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган гражданнар күпләп җыела торган урыннарны һәм югары куркыныч чыганаклары булган урыннарны билгеләү, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм территорияләр объектларына якын җирләрнең чикләрен билгеләү турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 29 октябрендәге 867 номерлы «Татарстан Республикасында халык арасында алкоголь продукциясен, сыра, тәмәке куллануны киметү һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча өстәмә чаралар турында» карары, Теләче муниципаль район Советының «Алкогольле продукция әйләнешен дәүләти җайга салу өлкәсендә Россия Федерациясенең норматив хокукый актларын гамәлгә ашыру турында» 2013 елның 27 июлендәге 160 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге Советының «Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм территорияләр объектларына якындагы территорияләрне билгеләү турында» 2013 елның 29 июлендәге 92 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 пунктның 2 юлын яңа редакциядә түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 2 | Белем бирү оешмалары | Стационар сәүдә объекты | Зонада объектка яки аерымланган территориягә керү юлыннан ким дигәндә 50 метр алып китү (ул булса) |
| | | Җәмәгать туклануы хезмәтен күрсәтүче объект | Зонада объектка яки аерымланган территориягә керү юлыннан ким дигәндә 60 метр алып тору (ул булса) |

- 2.6 пунктын яңа редакциядә кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны, гамәлдәге законнар нигезендә, түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Теләче муниципаль районы 422088, Олы Мишә авылы, Парк урамы, 3 йорт, һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында Олы Мишә авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Олы Мишә авыл җирлеге Башлыгы: Г. Ә. Маннапов

6 номерлы кушымта

Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге Советының 2016 елның « 16» декабрендәге 47 номерлы карары белән расланган

Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән МБМУ - Теләче муниципаль районы Түбән Саурыш башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе янындагы территория схемасы

